Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре“6 нчы “Кояшкай” балалар бакчасы”
муниципаль мәктәпкәчә белес бирү учреждениясе

| | |
|---|---|
| **Рассмотрено на педагогическом совете**<br>**От 31.08.2022г**<br>**Протокол № 1** | **Утверждаю**<br>**Заведующий МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»**<br>**__________________ Н.Н.Мугинова** |
| | **Введено в действие приказом заведующего МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»**<br>**От 31.08.2022г №136-ОД** |

# Беренче кечкенәләр төркеменең (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)
# 2022-2023 нче уку елына
# эш программасы


Төзүче тәрбиячеләр:
Ахмадеева Н.И.
Куликова П.В


Нурлат шәһәре
2022 ел

Эчтәлек


**1. Максатчан бүлек.**
**2.** 1.1. Аңлатмалы язу........................................................................................................................3
1.2 .Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле характеристикалар..........................4
1.3. 2-3 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре...........................................................................5
1.4.Төркемнең социальный паспорт...............................................................................................5
1.5. Төркемнең өстенлекле юнәлеш эшчәнлеге.............................................................................6
**2.Эчтәлекле бүлек.**
2.1 1нче кечкенәләр төркеме өчен оештырылган эшчәнлектә белем бирү өлкәләрентасвирлау.... ..6
1. “Социаль-коммуникатив үсеш”..................................................................................................6
2. “Танып-белү үсеше”....................................................................................................................12
3.“Сөйләм үсеше”............................................................................................................................19
4. “Сәнгать– эстетик үсеш”.............................................................................................................24
5. “Физик үсеш”...............................................................................................................................38
2.2.Комплекслы – тематик план......................................................................................................47
2.3.1 нче кечкенәләр төркемендә оештырылган эшчәнлектә вариатив формаларны куллану..........51
2.4. Әти-әниләр белән эш...................................................................................................................53
**3.Оештыру бүлеге**
3.1. Материаль-техник база................................................................................................................57
3.2. Методик кулланмалар.................................................................................................................57
3.3. Предметлы үстерешле мохит.......................................................................................................58
3.4. Көндәлек режим...........................................................................................................................59
3.5. Атналык оештырылган белем бирү эшчәнлеге.........................................................................60
3.6. Сәламәтләндерү эшчәнлеге.........................................................................................................61
3.7.Үзенчәлекле вакыйгалар,бәйрәмнәр,мероприятияләр................................................................63

## 1.Максатчан бүлек

### 1.1.Аңлатма язуы

Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2022-2023 уку елы)
Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:
Белем бирү өлкәсендә федераль дәрәҗәдә:
* 1.Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации».
* 2.Приказ МОиН РФ от 17.10.2013 №1155 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования».
* «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы» 08.07.1992 № 1560 - XII
* “Порядком организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования» (приказ Министерства образования и науки РФ от 30 августа 2013 года №26, 2.4. 3049-13)
* Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15.05.2013 г. №26 г. Москва «Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций».
* Законом РТ «Об образовании» от 22 июля 2013 года № 68 – ЗРТ
* Примерной основной образовательной программой дошкольного образования- Научный руководитель проекта А.Г.Асмолов. Одобренной решением федерального учебного-методического объединение по общему образованию от 20 мая 2015 г. №2/15-М. издательство «Национальное обраование», 2015г.
* Общеобразовательной программой дошкольного образоания «От рождения до школы» Под.ред. Н.Е. Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой.- М:МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014г
Белем бирү өлкәсендә региональ дәрәҗәдә:
· Балалар бакчасында Региональ белем бирү программмасы “Сөенеч- Радость Познание”/Р.К.Шәехова Казан: Мәгариф вакыт, 2016 ел.
С документами локального уровня:җирле дәрәҗәдә:
* Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад № 6«Солнышко» утвержден постановлением Руководителя ИК от 29.03.2012 года № 1579.
* План работы МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» на 2018-2019 учебный год.
* «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» на переходный период».

### Гомуми белешмә

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:** «Кояшкай» 6 нчыномерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.
**Кыскача атамасы:** «Кояшкай» 6 нчыномерлы балалар бакчасы МБМББУ
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**
*субъект РФ:*Татарстан республикасы
*индекс*: 423040
*населенный пункт:* Нурлат шәһәре
*урам: Гагарина*
*йорт:14 А*
*шәһәрнең федераль телефон коды: (*84345) *телефон:* 2-36-08
сайт: edu.tatar.ru
**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**
Мугинова Назлыгөл Насых кызы
**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**
1.Танып белү, сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы)
3.Сәламәтләндерү һәм профилактика чаралары

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының

сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС ДО) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

"Татарстан Республикасы халыклары телләре" турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камиллләштерүне дәвам итү.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: рус һәм инглиз теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы, логопед бүлмәсе.

Бүгенге көндә балалар бакчасында 4 төркем.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.30-18.30 сәгатькә кадәр эшли.

**1.2.Программаның төп бурычлары**-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтлеяшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә, мәктәптә укырга әзерләү, мәктәпкәчә яшьтәге баланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру. Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен, аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

**Бурычлар:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру/

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

• һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

• балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;

• тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;

• балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);

• мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;

• гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашуын тәэмин итү;

• балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;

.региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

**1.3. 2 – 3 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре**

Өченче яше белән барган балалар мөстәкыйльрәк була башлыйлар . Предметлы эшчәнлек, бала белән өлкәннәрнең ситуатив-эшлекле аралашулары үсә бара, кабул итүчәнлекләре, сөйләм, үз-үзләрен ирекле тотуның башлангыч формалары, уеннар, күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртүләре камилләшә.Аларның өлкәннәр белән аралашулары да

икенчерәк төсмер ала. Алар өлкәннәргә охшатып сөйләшергә тырышалар. Танып белүләре арта, сөйләм телләре яхшыра. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иң кечкенәләр төркемендә музыкаль эшчәнлекнең төп төрләре формалаша. Бу вакытта балада музыкага эмоциональ җавап бирү теләге туа. Аларның музыкаль активлыклары арта. Балалар җырга кушылып җырларга, биергә, гади уеннарны образлы итеп күрсәтә белергә омтылалар. Өлкәннәр белән күбрәк аралашкан саен сөйләм дә камилләшә төшә.

Аңлашылучы сүзләр артканнан – арта бара. Балалар өлкәннәр белән сөйләшкәндә үзләре үк җөмләләр төзеп сөйләшергә тырышалар. Актив сүзлектә сүзләр саны якынча 1000-1500 сүзгә җитә.

Өч яшь туларак сөйләм баланың яшьтәшләре белән аралашу чарасына әйләнә. Бу яшьтә балаларда уен, рәсем ясау, конструкторлау кебек яңа эшчәнлек төрләре формалаша.

*Уен процессуаль характер ала.* Анда иң мөһиме–эш-хәрәкәтләр.Балаларчынбарлыкка якынлаштырылган уен предметлары белән уйныйлар. Өченче яшьнең урталарында бер предметны икенчесе белән алыштырып уйнау күнекмәләре барлыкка килә.

Сурәтләү эчшәнлеге барлыкка килү баланың ниндидер предметны сурәтләргә теләген белдерергә сәләтле булуы белән аңлатыла. Гадәттә бу кешене “башаяк” (әйләнә һәм аннан китүче сызыклар) формасында сурәтләү.

Өченче яшьтә шулайк ук балаларның күрү һәм ишетү сәләтләре дә яхшыра. Бу вакытта алар формасы, төсе , биеклеге буенча төрле предметларны , җырларны, көйләрне аералар. Өч яшькә балалар туган телнең барлык авазларын беләләр, тик аларны бик нык бозып әйтәләр.

Ишетеп зиһенгә алу сәләте бигрәк тә фонематик ишетү камилләшә. Бу балаларга кайбер биремнәрне хатасыз үтәргә мөмкинлек бирә. 2-3 предметны формасы, зурлыгы, төсе буенча сайлап алу, көйләрне аеру, җырлау.

Балалар яшьтәшләренең эмоциональ халәтенә бик җиңел биреләләр. Шулай да бу чорда балада ирекле тәртип формалаша башлый. Балаларда оялу, горурлык хисләре уяна. Бала үзен өлкәннәрдән аерым шәхес итеп тоя. 2 яшьлек балаларның үз “Мин” е формалаша.

Кризис күп кенә тискәре күренешләргә сәбәпче була: негативлык, кирелек, еш кына өлкәннәр белән мөнәсәбәтләрнең бозылуы һ.б. Кризис берничә айдан 2 елга кадәр сузылырга мөмкин.

**I.4.Төркемнең социаль паспорты**

| *Төркемдәге балалар саны* | *Татарлар* | | | | *Руслар* | *Катнаш гаиләләр* | *Чуваш* |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *Татарлар* | *Сөйләшә* | *Аңлый* | *Аңламый* | | | |
| 16 | 12 | 12 | 16 | 0 | 4 | 2 | 0 |

**1.5.Программаны үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр**

1 кечкенәләр төркемендә белем бирү эшчәнлегенең максаты булып тәрбияләнүчеләрнең дәүләт белем бирү программасын үзләштерүе тора. Без мониторингка зур әһәмият бирәбез.Тәрбиячененң максаты – балаларга системалы рәвештә белем бирү һәм балада мәктәпкә әзерләү төркеменнән чыгып киткәндә мәктәптә уңышлы уку өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр булдыру:

• Бала тирә- юньдәге предметлар белән кызыксына, уйный, хәрәкәт итә,үз максатына ирешергә тырыша

• Көнкүрештә кулланыла торган предметларның ни өчен кирәклеген белә һәм аларны куллана белә

• Актив сүзлек запасы барлыкка килә, өлкәннәрнең аңлаешлы соравына җавап бирә, үзендәге мәгълүматны уртаклаша

• Уеннар вакытында һәм көнкүрештә сөйләшә

• Яшьтәшләре белән кызыксына, аларны күзәтә, хәрәкәтләрен кабатлый

• Шигырьләр, җырлар, әкиятләр белән кызыксына, рәсемнәр карый, музыка астында хәрәкәт итә, сәнгать әсәрләренә соклана

• Балада эре моторика үсә, бала төрле хәрәкәтләр башкарырга омтыла (йөгерү, үрмәләү, атлап чыгу)

**2.Эчтәлекле бүлек**

**2.1.1нче кечкенәләр төркеме өчен оештырылган эшчәнлектә белем бирү өлкәләрен тасвирлау.**

Планлаштыру интеграция принциплары, төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

**Программаның эчтәлеге шәхесне төрле яклап үстерүгә юнәлтелгән һәм түбәндәге белем бирү өлкәләрен үз эченә ала:**

**“Социаль-коммуникатив үсеш”**

**“Танып белү" үсеше”**

**“Сөйләм үсеше”**

**“Нәфис-нәфасәти үсеш”**

**“Физик үсеш”**

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге (1 нче кечкенәләр төркемендә белем бирү өлкәләренең төп максатлары һәм бурычлары)**

**1.“Социаль-коммуникатив үсеш”**

**“Социаль-шәхси үсеш ”** белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагыберенчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели.

**Уен эшчәнлегенең үсеше.**

Балаларның бергәләп уйнауларын хуплау. Төрле уеннарга карата кызыксыну уяту. Күңел ятуына карап 2-3 кешенең берләшеп уйнауларына булышу. Уеннар процессында әйләнә-тирәгә кызыксыну уяту.

**Сюжетлы-рольле уенар.**

әйләнә-тирә тормыштагы темаларга, әдәби әсәрләрнең эчтәлегеннән чыгып, төрле уенар оештырырга булышлык итү, аерым гамәлләрне бер сюжетка берләштерү юлы белән балаларның уен тәҗрибәсен баету.

Балаларның роль сайлый белү, уенчыклар белән берничә үзара бәйләнгән гамәлләр башкара алу осталыкларын үстерү.

Озакка сузылмаган күмәк уеннарда бердәм эш итү, дус, тату уйнау күнекмәәрен үстерү. Теге яки бу роль өчен мөстәкыйль рәвештә атрибутлар сайлауга омтылышларын хуплау.

Уеннарда төзелеш материалларын кулланырга, гади генә агач һәм пластмасса коонструкторлардан, табигый материаллардан файдаланырга, алар белән төрлечә эш итә белергә өйрәтү.

**Хәрәкәтле уеннар**.

Балаларның хәрәкәт активлыкларын үстерү.

Кагыйдәле уеннар оештыру. Уенчык машиналар , арбалар, туплар һәм шарлар белән мөстәкыль уйнарга күнектерү. Үрмәләү, шуышу күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтләрне җиңел, оста, җитез итеп башкаруларына ирешү. Хәрәкәт төрләрен үзгәртеп һәмкатлаулырак кагыйдәле уеннар уйнау. Балаларда хәрәкәтләрне яраштыру, тирә-юньдә ориетлаша һәм уенның кагыйдәләрен үти белү күнекмәләре тәрбияләү.

**Театральләштерелгән уеннар.**

Балаларда уеннарны сәхнәләштерү эшчәнлегенә кызыксыну уяту, аларны уздыру өчен шартлар тудыру. Өлкәннәр һәм зуррак балалар көче белән оештырылган сәхнәләштерелгән уеннар, курчак спектакльләрендә вакыйга агышын игътибар белән күзәтә белү күнекмәләрен ныгыту. Сәнгать матералларын образлы итеп җиткерү юлы белән балаларны мавыктыру, шук ук вакытта уенның төрле формалары ярдәмендә сәхнәләштерү процессына тарту.

Персонажларның характерлы гамәлләрен охшатып уйнарга өйрәтү . Балаларны өстәл театры курчакларын йөртү алымнары белән таныштыру. Костюм атрибутлары һәм элементлары белән гамәлләр башкару теләге тудыру.

Чыгыш өчен урын әзерләп, курчаклар һәм яшьтәшләре алдында чыгыш ясау теләге тудыру.

**Дидактик уеннар.**
Балаларның предметланы төсе һәм зурлыгы(2-3 төрдәге зур һәм кечкенә шарлар) буенча аеру. 2-3 төсне билгеле бер эзлеклелектә чиратлаштырып, бөжралар кечерәя бару тәртибендә манарачык төзү күнекмәләрен ныгыту. Күмәк дидиктик уеннарда акрынлап катлана баручы кагыйдәләрне, хәрәкәтләрне башкарырга өйрәтү.
**Әхлак тәрбия нормалары белән таныштыру.**
Балаларга әхлак тәрбия бирү өчен шартлар тудыру.

Өйдә, балалар бакчасында, урамда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Яхшылык һәм начарлык төшенчәләре белән таныштыру.

Яшьтәшләрен җәлләү, кочаклау, ярдәм итү омтылышларын хуплау. Кешелеклелек, дуслык, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләүгә булышлык итүче ситуацияләр тудыру. Аралашу әдәбенә өйрәтү.

Балаларда бер-берсенә карата дустанә мөнәсәбәттә булу, яхшы һәм начар гамәлләрне дәрес бәяли белү тәҗрибәсе формалаштыру.
Әдәплелеккә өйрәтү: исәнләшү, саубуллашу, ярдәм өчен рәхмәт белдерү күнекмәләрен ныгыту,

Үзара дус яшәргә, уенчыклардан, китаплардан уртак файдаланырга, бер-береңә ярдәм итешергә өйрәтү.

**МИН образы.**

МИН образын формалаштыру. Үзеңне аңлый белергә ярдәм итү. Үзләренә кагылышлы төрле мәгълүмәт бирү(син-кыз)
**Гаилә.** Балалар белән гаилә әгъзалары,аларның бер-берсенә карата кайгыртучанмөнәсәбәттә булуларын сөйләү.
Балалар бакчасы. Балалар бакчасындагы хезмәткәрләрнең исемнәрен, әтиләренең исемнәрен исләренә төшерү. Төркем бүлмәсен тәтиптә тотарга күнектерү. Бина эчендә, мәйданчыкта ориентлаша белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Туган ил .** Үзләренең туган шәһәренең исемен әйтергә өйрәтү.Ял көннәрендә кайлардабулулары турында сөйләргә теләк уяту.
**Өлкәннәр хезмәте.**Балаларның өлкәннәр хезмәте,аларның һөнәрләре турындабелемнәрен киңәйтү. Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.
**“Хезмәт” белем бирү өлкәсе.** Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеген көчләреннәнкилгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.**

Билгеле бер тәртиптә мөстәкыйль киенергә, чишенергә өйрәтү.

Балаларны пөхтәлеккә, киемнәрдәге җитешсезлекне күрергә һәм өлкәннәр ярдәме белән аны бетерергә өйрәтү.Үзара ярдәмләшү тойгысы тәрбияләү.
**Хуҗалык-көнкүреш хезмәте.**
Гади генә эшләрне, кушкан йомышларны мөстәкыйль рәвештә башкарырга күнектерү. Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта тәртип һәм чисталык сакларга өйрәтү. өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.

**Табигатьтәге хезмәт.**

Табигать почмагында үсемлекләрне карауда катнашу теләге тәрбияләү. өлкәннәр ярдәме белән кошларны ашатырга. Бүлмә гөлләренә су сибәргә, кардан юлларны чистартырга, коелган яфракларны җыярга, эскәмияләрдән карны себереп төшерергә өйрәтү. Өлкәннәр хезмәтенә уңай караш тәрбияләү. Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеген көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру. Таныш һөнәр кешеләренә хөрмәт тәрбияләү эшен дәвам итү.

### *«Тормыш иминлеген саклау»* календарь тематик планы

| ае | Атнасы | № һәм эшчәнлек темасы | Максат | Методлар һәм алымнар | Оештыру формасы | Интеграл-ү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| сентябрь | | Адаптация чоры<br>Төркемгә балалар өйрәтү | | Әңгәмә, ата-аналарга анкеталар, консультацияләр | тәрбияче инициативасы буенчауеннар | |
| октябрь | 2 | №1 Танышу бәйрәме | Танышу вакытында кулланыла торган кайбер кагыйдәләр белән танышу һәм ныгыту. | Аңлату,Күрсәтү,<br>Дид. Уен,х.а.и.уку, Үз үрнәге<br>Иллюстративматериал,ял | Игра<br>Беседа<br>групповое занятие | Танып белү,<br>Соц-үМат.әд.уку |
| ноябрь | 2 | №4 доктор Айболит | Балаларны кайбер кадый һәм кисә т орган предметлар белән таныштыру. | Аңлату,Күрсәтү,<br>Дид. Уен,х.а.и.уку, Үз үрнәге<br>Иллюстративматериал,ял | Игра<br>Беседа<br>групповое занятие | Танып белү,<br>Соц-үФизик тәр.,сынлы сән. |
| Декабрь | 3 | № 5 Чыршыкай | Балаларга тиздән бәйрәм чыршы кунакка килүе турында аңлату. Чыршы ылыслары кадый, уенчыкларын тоарга ярамый. | | | Танып белү,<br>Соц-үМат.әд.уку,<br>Сынлы сән. |
| гыйнвар | 3 | № 7 Кешеләрнең хәрәкәтләрен күзәтү | Урамда юл кагыйдәләре белән таныштыру | Аңлату,Күрсәтү,<br>Дид. Уен,х.а.и.уку, Үз үрнәге<br>Иллюстративматериал,ял | Игра<br>Беседа<br>групповое занятие | Танып белү,Мат.әд.уку, Тор. Им.н са. |
| Февраль | 2 | № 8 Рәсем «Юлда йөри аяклар» | Урамда юл кагыйдәләре белән таныштыру | | | |
| Март | 3 | № 9 Транспорт | Йөк транспорты һәм җиңел машина белән танышү | | | |
| Апрель | 4 | № 10 Светофор | Светофорны карау һәм төсләрен ныгыту. | Аңлату,Күрсәтү,<br>Дид. Уен,х.а.и.уку, Үз үрнәге<br>Иллюстративматериал,ял | Игра<br>Беседа<br>групповое занятие<br>Подгрупповое | Тан.б.,<br>С– р уен<br>Мат.әд.укуТор. им. сак. |
| Май | 3 | № 11 Бала һәм табигать | Тере табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, бәйләнешен , кагыйдәсен аңлату. | | | |

Юл кагыйдәләренә өйрәтү планы

| Ае | Темасы һәм максаты | Атнасы | Тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге |
|---|---|---|---|
| О К Т Я Б Р Ь | "ЙӨК МАШИНАСЫ" Йөк машинасын башка машиналардан аера белергә өйрәтү. Йөк машинасының арбасы турында мәгълүмат бирү. | 1 | Х/У "Машиналар йөри" Максат:машиналарның юлда йөрүләрен аңлату |
| | | 2 | Х/У "миңа йөгерегез" |
| | | 3 | Йөк машинасын күзәттү. Әңгәмә ситуация "Машиналар нәрсәдән тора" |
| | | 4 | Автомобильләр һәм йөк машиналарын карау Максат: транспорт төрләрен аера белергә өйрәтү |
| Н О Я Б Р Ь | "УРАМНЫҢ КИҢ ҺӘМ ТАР ЮЛЛАРЫ" Балаларга киң юлда машиналар, ә тар юлда кешеләр йөрү турында аңлатма бирү.машинаның тиз йөрүен аңлату. Кызыл һәм яшел төсләр турында белемнәрен ныгытуны дәвам итү | 1 | Уен "Мин әйткән машинаны эзлә" Максат: йөк һәм җиңел машиналарны аера белүләрен ныгыту |
| | | 2 | Уен ситуациясе: "Уңышны җый" Максат: йөк машинасында ниләр ташу турында аңлату |
| | | 3 | Конструкцияләү "Киң һәм тар юллар" |
| | | 4 | Уен күнегү "Кем игътибарлы?" |
| Д Е К А Б Р Ь | "КЕШЕЛӘР НӘРСӘГӘ УТЫРЫП ЙӨРИ" Максат: йөк машиналарында песок, бәрәңге, алма һ.б. ташу турында ,ә кешеләр җиңел машиналарда утырып йөрү турында белемнәрен ныгыту. | 1 | Уен: "Мин атаган машинаны тап" Максат: җиңел һәм йөк машиналарын аера белергә өйрәтү. Х/У "Кошлар һәм автомобиль" |
| | | 2 | Уен күнегү "Кем игътибарлы?" А.Барто "Грузовик" |
| | | 3 | Д/У "Уйла нинди машинада алып барасың" С/р уен "Шофер" күзәтү |
| | | 4 | Конструкцияләү "Киң һәм тар юллар". "Кышын урамда" рәсемен карау |
| Я Н В А Р Ь | "ПОЕЗД ҺӘМ ТИМЕР ЮЛЫ" Поезд кебек транспорт төре белән танышу. Поездның тимер юлдан йөрүен, озын һәм вагоннары булуын, кешеләр йөртүен аңлату. Машинист һөнәре белән таныштыру. | 1 | Уен "Безгә кунаклар килә" Поездны карау. Поезд уены |
| | | 2 | Уен "Минем бар рулем" Максат: сүз байлыгын үстерү |
| | | 3 | Уен "Йоклый торган поезд" Уен күнегү "Паровоз" |
| | | 4 | Конструкцияләү "тимер юлы төзибез" |
| Ф Е В Р А Л Ь | "НӘРСӘ УЛ ТРАМВАЙ" Трамвай транспорт төре буларак таныштыру. Аны башкалардан аера белергә өйрәтү. | 1 | Уен "Чанада" Трамвайны карау Х/У "Поезд" |
| | | 2 | Конструкцияләү "Автобус, трамвай" Әңгәмә ситуация "Кышын ни өчен юл куркыныч" |
| | | 3 | Д/У "Паровоз" |
| | | 4 | Уен "Поезд һәм туннель" Х/У "Чыпчык һәм автомобиль" |
| М А Р Т | "ЮЛДА ДУСЛАР" Светофор белән юл кагыйдәләрен өйрәтү. Светофорның билгесен аңлату. | 1 | Д/У "Светофорны җый" Х/У "Паровоз һәм машина" |
| | | 2 | Д/У "нәрсә белән алып барасың уйла", "Дөрес, дөрес түгел" |
| | | 3 | Уен "Машинистлар-шоферлар" Конструкцияләү "Машиналарга юл" |
| | | 4 | Д/У "Тап һәм җый" Х/У "Паровоз һәм машина" |
| А П Р Е Л Ь | "САК БУЛ-ЮЛ!" Транспорт турында белемнәрен ныгыту. Юл кагыйдәлрен өйрәтү. Кызыл төскә ярамый, яшел мөмкин. | 1 | Уен "Ничек машина җәнлекләрне йөрткән" Д/У "Мөмкин- тоела" |
| | | 2 | Машинаның йөрүен күзәтү Х/У "Чыпчык һәм автомобиль" |
| | | 3 | Транспорт мәйданчыгында зурлар төркеме балалары артыннан күзәтү |
| | | 4 | Уен "Безгәкунаклар килә" |

| | | | |
|---|---|---|---|
| М А Й | "ЯРЫЙ-ЯРАМЫЙ"<br>Юл кагыйдәләрен сюжетлы картиналар кулланып ныгыту. Транспорт төрләре , светофор турында шигырьләрне, табышмакларны кабатлау. | 1 | "Шофер" уенын күзәтү<br>Конструкцияләү "Трамвай" |
| | | 2 | Д/У ""Ярый-ярамый", "Светофорны җый" |
| | | 3 | Конструкцияләү "Автобус"<br>Транспорт мәйданчыгында уеннар |
| | | 4 | Транспорт мәйданчыгында уеннар |

Максат: Социаль- иҗтимагый тәрбия турында беренче күзаллауны үзләштерү.

- Балаларда төрле уеннар белән төрле кызыксынучанлык тәрбияләү.
- Бер-берсе белән уртак тел табуларыны ирешү.
- 

| ***Ай*** | ***Сюжетлы-рольле уенннар<br>Хәрәкәтле уеннар<br>Дидактик уеннар<br>Сәхнәләштерелгән уеннар*** | ***Балаларны бер-берсе белән уртак тел табарга җылы мөнәсәбәттә була белергә өйрәтү.*** | ***Гаилә әгъзалары арасында булырга тиеш гомумкешелек кыйммәтләренең өстенлеге турында күзаллау булдыру.*** |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Адаптация чоры.Төркемгә балалар өйрәтү<br><br>Әңгәмә, ата-аналарга анкеталар, консультацияләр.<br>Тәрбияче инициативасы буенчауеннар | | |
| Октябрь | -*С/р уен* "Яңа курчак", "Курчакны киендерәбез", "Курчакны ашатабыз", Курчакны юындырабыз"<br>-*Д/уен* "Туп нинди төстә?"<br>"Бу нинди яшелчә?", "Бу кем?","Бу нинди савыт- саба?"<br>-*Х/уен* "Флажокка кәдәр йогер","Очты-очты".<br>-Бармак театры "Калач"<br>Курчак театры "Бәлли бәү" | "Кунак"<br>Әңгәмә:"Ягымлы сүзләр"<br>Әкият "Кабартма" | Ситуация "Курчак Алсу нәрсә кигән?"<br>"Чәбәкәй" |
| Ноябрь | -*С/р уен*"Курчакны йоклатабыз" , "Курчак уянды"<br>-*Д/уен* "Баштан нәрсә киябез","Күрсәт әле үскәнем", "Рәсемдә нәрсәләр ясалган?", "Бу нәрсә?".<br>-*Х/уен* "Җил исә", "Ак куян" | "Кабартма"(Ак калач) уены .<br>"Әйе-юк" .<br>*Д/уен* "Мин әйтәм , сез күрсәтегез". | Әңгәмә:"Исемең матур"<br>"Бармак" уеннары<br>"Күрсәт әле үскәнем" |
| Декабрь | -*С/р уен* "Курчак авырып киткән", "Төшке ашка курчак кунак көтә", "Курчакны савыт-саба юарга өйрәтәбез"<br>-*Д/уен* Җәяүлеләр", "Бу нинди транспорт?","Кушканны үтә,"Моны кая кияләр?"<br>-*Х/уен* "Көн-төн", "Чеби белән песи"(10), "Очты-<br>очты"(10).<br>*Күләгә театры* "Кәҗә бәтиләре һәм бүре"<br>*Курчак театры* "Өч аю" | *Д/уен*"Серле сандык"<br>Уен "Марат монда кил"<br>*Х/уен* "Карусель"<br>Әңгәмә "Уйнарга яратабыз"<br>"Карусель"<br>"Тынлык уены" | *Д/уен* "Мин әйтәм син тап".<br>*Х/уен*"Аюлар һәм балалар"<br>"Бармак"уеннары |
| Январь | -*С/р уен* "Курчакны машинада йөртәбез"<br>-*Д/уен*"Бу кайчак була?","Җылы-суык", "Уенчык нинди?", "Тәрҗемәче"<br>-*Х/уен* "Җил исә","Кем юк?","Кем тизрәк","Кошлар".<br>*Бияләй театры* "Шалкан". | Ситуация "Дустыңа шар бир"<br>"Чылбыр" | "Бармак"уеннары<br>Уен "Син кемне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Февраль | -*С/р уен* “Шоферлар”,”Шоферлар”<br>-*Д/уен* “Мин күрсәтәм сез әйтегез”, “Нинди?”<br>-*Х/уен* “Светофор” , “Үз төсеңне тап, “Песи һәм тычканнар”, “Маэмай” “Чуар тавык”әкияте буенча өстәл өсте театры.” Кәҗә бәтиләре һәм бүре” өстәл өсте театры. | Уен “Үзеңне макта”<br>Җырлы биюле уен “Парлашып калу<br>Уен “Киеменнән таны” | “Гаилә чәчәге” уены<br>“Бармаклар” уеннары. |
| Март | -*С/р уен* “Машинада бару” “Автобус белән бару” “Кызыл, сары, яшел”, “Светофор”<br>-*Д/уен*”Рәсемне ясап бетер”, “Автобусны ясап бетер”, “Төсне тап”,”Бу әйбер нигә кирәк?”,“Мин әйтәм, син тап”<br>-*Х/уен* “Машина һәм чыпчыклар”, “Трамвай”, “Әбәкле”,”Энә, җеп, төен”, “Куык”<br>*Өстәл театры* “Йомры икмәк” | Уен “Чәбәкәй”<br>Уен”Эндәшмә<br>Балаларны уенга җыю өчен күнегүләр”Уңган балалар” | “Бармак”уеннары<br>*Д/уен* “Бу кем?”,“Кем юк?” |
| Апрель | -*С/р уен* “Гаилә”, “минем гаиләм”, “Җил һәм яфраклар”<br>-*Д/уен* “Тамчы там” ,”Әйе юк”.Табышмаклар, кирәкле сүзен әйт ,”Кия сала”.<br>-*Х/уен* “Аю-бүре”,”Ал кирәк-гөл кирәк,”Куышлы”, “Үз төсеңне үзләп тап”<br>-*Сәхнәл.уен* “Чыпчыклар һәм песи”. | Уен “Иптәшеңне сыйла”,”Ак калач” уены.<br>Җырлы биюле уен “Минем күлмәгем матур” | Табышмаклар.<br>*Д/уен* “Нишли?”. |
| Май | -*С/р уен* “Төлке”, “Ат”, “Кемнең әнисе"<br>-*Д/уен* “Күбрәк-әзрәк”, “Охшаганмы - юкмы?”,”Шулай буламы-юкмы?”, Дөрес светофорны эзләп тап” , “Үз парыңны тап”.<br>-*Х/уен* “Тигез юл буйлап”,” Мәче Һәм тычканнар”, Үз төсеңне тап”, “Трамвай”,”Инеш аша үтәбез”. | Уен “Курчак өчен бүләкләр сатып алу” , “Ак калач” | “Бармак” уеннары , “Серле тартма” , “Гаилә чәчәге” уены . |

**«*Хезмәт*»календарь- тематик планы**

| Ай саен | Көн саен | Эшчәнлекнең темасы | Максат | Методлар һәм алымнар | Эшчәнлек формалары | Интеграллэштерү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Сентябрь | | Төркемгә балалар өйрәтү. Адаптация чоры. | Әңгәмә, ата-аналар белән анкеталар уздыру, консультацияләр | Тәрбияче инициативасы буенча уеннар (сюжетлы-дидактик). Күңел ачу эшчәнлекләре | | |
| | | Хезмәт эшчәнлегенүстерү | Чишенү һәм киенү тәртибенә өйрәтү һәм салган киемнәрне билгеле бер тәртиптә этереп кую | Аңлату, күрсәтү, матур әдәбият әсәрләрен | Уен, Әңгәмә: ярты төркемләп, төркемләп, | Сәламәтлек Танып белү Сөйлшәм |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Үз хезмәтеңә, өлкәннәр башка кеше хезмәтенә, аларның эш нәтиҗәләренә сакчыл караш тәрбияләү.<br><br>Өлкәннәр хезмәте турында беренче күзаллауларын формалаштыру, аның роле. | күнекмәләрен формалаштыру. Пөхтәлеккә күнектерү. Гади булган хезмәт күнекмәләрен куллануны күнектерү.<br><br>Уен бүлмәсендә тәртип булдыруны таләп итү, уен тәмамлануга уен материалларын урынына кую. Салфет һәм ипи(иписез) савытларын зурлар ярдәмен белән һәм алар янында аш өстәлләренә куюны формалаштыру.<br><br>Өлкәннәр хезмәте белән кызыксынуны булдыру.Аларга булышу теләге уяту. Мәйданчыкта һәм төркемдә өлкәннәрнең ничек җәнлекләрне һәм үсентеләрне каравына игътибарлылыкларын үстерү. Хезмәт күнекмәләрен атау һәм таный белүне өйрәтү(тәрбияче ярдәмчесе савытлар юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алымаштыра һ.б.) | уку,<br>Мактау,<br>Ата-аналар җыелышында әңгәмәләр,<br>ял итү чаралары,<br>Үз үрнәк ,<br>проблемалы ситуацияләр | индивидуаль | телен үстерү<br>Социальләштерү |

<u>**2. “Танып белү үсеше”**</u>

**Танып белү өлкәсе**

Балаларның танып белүен үстерүгә юнәлтелгән максатларын тормышка ашыру һәм интелектуаль үсү өчен түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә кирәк.

- сенсорик тәрбия
- иҗади эшчәнлекне үстерү
- гади математик күзаллауларны формалаштыру
- бербөтен дөнья картинасын, балаларның дөньяга карашын киңәйтүне формалаштыру.

**Танып-белү, тикшерү һәм иҗади эшчәнлекне үстерү**

Тикшерү, кызыксынуны хуплап гади күзәтүләр үткәрү. Төрле ысуллар һәм тәҗрибәләр ярдәмендә предметны тикшерү (бата-батмый).

Катлаулы булмаган төзелешләрне анализлау. Конструктив осталыкларын тормышка ашыру.

Төп төзелеш кисәкләрен аера, таный, исемен атый белүне ныгыту(кубик, пластина, кирпеч, цилиндр). Яңа төзелешләр уйлап чыгару сәләтен үстерү. Төзелештә төп кисәкләрнең төрле төсен куллана белү. Әйбәт килеп чыккан төзелешкә шатлану хисе уяту.

Үзлектән уйлап чыгарып төзү осталыгын үстерү.

Балаларны уйнаганнан соң төзелеш кисәкләрен чиста-пөхтә итеп җыештырып куярга күнектерү.

**Дөнья картинасын үзләштерү, белем дәрәҗәсен үстерү.**

Балаларның тирә-юньдәге предметлар һәм аларның кулланышы турындагы белемнәрен киңәйтү. Предметларның төсен, зурлыгын, формасын , авырлыгын, аларның балага карата кайда урнашуларын билгеләргә өйрәтү. Яхшы таныш әйберләрне төркемнәргә аерырга өйрәтү.

**Табигать белән таныштыру**.

Табигать күренешләре белән кызыксыну уяту.

Балаларны һава торышын билгеләргә һәм әйтеп бирергә өйрәтү, ел фасылларының характерлы үзенчәлекләре белән таныштыра башлау(яфраклар коела, кар ява, гөрләвекләр ага һ.б.)

Туган якның кайбер үсемлекләре турындагы элементар кузаллау формалаштыру. Яфрак формасы, чәчәк төсе буенча берничә бүлмә гөленең исемнәре белән таныштыру. Тышкы кыяфәтләре һәм тәмнәренә карап, кайбер яшелчә һәм җиләк-җимешләрне тану күнекмәләре формалаштыру.

Йорт хайваннары һәм аларның балалары хәрәкәт итү һәм туклану үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Кыргый хайваннар турында башлангыч төшенчәләр бирү. Кайбер бөҗәкләр белән таныштыру.

Суның, комның, карның характерлы үзенчәлекләре белән таныштыру.

Тере һәм тере булмаган табигать арасында булган бәйләнешләрне ачыклау.

Табигатькә сак караш тәрбияләү, аның матурлыгына соклану.

| **Тема** | **Бурычлар** |
|---|---|
| **Октябрь** | |
| КӨЗГЕ ТАБИГАТЬ | 1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР | 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алутурында күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәреһәм алар ның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү. |
| Минем исемем бар | 1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә каратаягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү |
| Бу — мин | 1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыклау һәм ныгыту;<br>2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. |
| Яраткан уен бүлмәбез | 1) балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерү, уен (төркем) бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, «һәр әйбернең үз урыны» дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;<br>2) сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү;<br>3) җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләү. |
| | |

| | |
|---|---|
| **Ноябрь** | |
| Ап-ак кар ява<br>5 | 1) балаларны кар һәм аның үзлекләре (ак төстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның сүз байлыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |
| «Безнең урам»<br>12 | 1) балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) урамга соклану хисе тәрбияләү |
| Электр лампасы белән таныш тыру | 1) электр турында балаларга гади төшенчә бирү (электр тогы электр чыбыкларында «яши»; утны яндыру өчен, өзгечкә (выключательгә) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток килә); электр, ток,чыбык,өзгеч (выключатель) сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү, ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү;<br>3) сакчыллык тәрбияләү. |
| Әниләр бәйрәме | Әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. Аларның хезмәте белән таныштыру. |
| **Декабрь** | |
| Гирлянда | 1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күз аллауларын ныгыту, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;<br>3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| Яшел чыршы | 1) балалар белән бергәләп чыршыны карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| Чыршы бизибез | 1) балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тоюсәләтен үстерү;<br>3) чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| Без музыка залында | 1) чыршы бәйрәменә әзерләнү: балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары, аларның материалы, төсе, формасы белән таныштыру; чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырыйсүзләре хисабына сүзлекне активлаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда эстетик хисләр тәрбияләү. |
| **Гыйнвар** | |
| Алсу урамга җыена | 1) балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертү, урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдырырга өйрәтү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| Күгәрченнәр, чыпчыклар — безнеңнәни кошчыклар | 1) мәйданчыктагыҗимлеккәкилгәнкошларныкүзәтү, исемнәренәйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар-каравазияртемнәренәчыкәйтергәкүнектерү;томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләрехисабынасүзлекнебаету;<br>2) балаларныңигътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларгаҗавапбирүосталыгынүстерү;<br>3) кошлартурындакайгырту, аларгаярдәмитүтеләгетәрбияләү. |
| Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча) | 1) рәсемне карарга, рәсемдәге предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү;<br>2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3) сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. |
| **Февраль** | |
| Безнеңапа | 1) тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш-хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү (савыт- |

| | |
|---|---|
| (тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтенкүзәтү) | саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.), сүзлекне активлаштыру, яңа сүзләр белән баету, уенчыкларны күләмнәре (зур, кечкенә) буенча классификацияләргә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгына ирешү;<br>3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләү. |
| «АЛСУ БӘЙРӘМГӘ ҖЫЕНА» ДИДАКТИК УЕНЫ | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: *ефәк, ак, чәчәкле* кебек яңасүзләр кертү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларныишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерү; |
| Безнең әтиләр (сюжетлы рәсемнәркарау) | 1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| Дидактик уен “Әниләр һәм әтиләр турында сөйлә” | Әти-әниләре турында алган белемнәрен гомумиләштерү. Үз әти-әниләре турында фикер алышырга өйрәтүне дәвам итү. Хәрмәт тәрбияләү |
| Безнең әниләр (сюжетлы рәсемнәр карау) хөрмәт тәрбияләү. | 1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, |
| Яз, яз килә... | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| Матрёшкалар | 1) балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар) белән таныштыруны дәвам итү, матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру, балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңларга күнектерү;<br>2) игътибарны, хәтерне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну, уенчыкларга (матрёшкага) карата сакчыллык тәрбияләү. |
